РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Микулинского сельского поселения
Азнакаевсокго
муниципального района

ул. Советская д.74
с. Микулино, Азнакаевский район,
423306
Тел ( Факс) : (8 – 85592) 33 – 2 – 09

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
Советы
БАШЛЫГЫ

Совет урамы, йорт 74,
Микулино авылы, Азнакай
районы,423306
Тел(факс) :(8 –85592) 33 – 2 – 09

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

21.03.2017. — №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Микулино авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Микулино авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләүне керешергә.

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында

-423306, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Микулино авыл җирлеге, Благодатный Бистәсе, Березовая ур., 7 йорт адресы буенча урнашкан 16:02:230103:14 кадастр номерлы җир кишәрлеге өчен территориаль зонаны ОД1 күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонасыннан Ж1 индивидуаль торак төзелеше зонасына үзгәртергә;

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм вакытларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык — И.А. Такиулин

Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башлыгының 21.03.2017 ел, №4 карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Микулино авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү буенча эшләрне башкаруның якынча сроклары**

| N | «Микулино авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару срогы |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен оештыру. | I кварталы 2017 |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволар кисәтүләренә шәрехләр әзерләү. | I кварталы 2017 |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Гавами тыңлаулар уздыру.<br>Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге төзелешенең җирдән файдалану кагыйдәләренә һәм аңа мәҗбүри кушымталарга (гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә) җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын авыл җирлеге Советына раслау яисә кире кагу турында һәм аны кабат эшләп бетерү датасын күрсәтеп, эшләп бетерүгә җибәрү турында белешмә. | I - II кварталы 2017 |